Тема: Госман Бакирның “Кинога барганда” хикәясе. 1нче бүлек. 14 нчы бит, 1 нче күнегү.

Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елның 12 мартында Татарстан Республикасының Арча районы Югары Курса авылында туа. Туган авылындагы мәдрәсәне тәмамлагач, уналты яшьлек Госман үзенең мөгаллимлек эшен башлап җибәрә. Г. Бакир балалар йортында укытучы-тәрбияче булып эшләгән елларда ныклап торып әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый, балалар өчен беренче хикәяләрен яза.



1928-1936 елларда “Беренче җиңү”(1928). “Яшәсен яшьләр”(1934), “Безнең рапорт”(1936), “Сафа балалары”(1935) дигән сәхнә әсәрләрен иҗат итә, 1936 елда “Урак өсте” дигән хикәяләр җыентыгын бастыра.

- 1942 елда үзе теләп фронтка китә. Сугышта күрсәткән батырлыклары һәм хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз, Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләренең күбесе авыр сугыш елларын һәм сугыштан соңгы чорда балалар һәм мәктәп тормышын чагылдыра. Аның әсәрләре сәнгатьчә, балалар яратып укырлык итеп язылганнар.

# Яңа сүзләр.

- яфрак ярган тополь – распустивший листья тополь
- тәмле ис – приятный запах
- тырышып-тырышып – старательно
- кушты – велела
- өлгерә  алмыйм – не успеваю
- бәрәңге әрчеде – почистил картошку
- очратты – встретил
- авызы ерылган – улыбается
- аяклары җиргә тими – ноги под собой не чует

# Сорауларга җавап бирү

- Шамил әнисенә нәрсәләр эшләргә булышты?
- Салих кая бара иде?
- Шамилне эшчән, игътибарлы, әдәпле малай дип әйтеп буламы?
- Фикерегезне хикәядәге мисаллар белән раслагыз.

**Тексттан план пунктларына туры килгән абзацларны табып укыгыз.**

- 1. Көн матур иде.
- 2. Әнисе эшләр кушты.
- 3. Салих белән очрашу.
- 4. Салих та кинога барачак.

Бу сыйфатларның кайсысы Шамилгә туры килә?

- Эшчән, ялкау, хезмәт сөя, игътибарлы, әдәпле, тупас, игелексез, игелекле, мәгънәсез, ярдәмчел, тырыш, сабыр, кеше хәленә керә белүчән.

- -Укучылар, бүген  без сезнең белән бик эчтәлекле хикәя белән таныштык.
- -Әйдәгез соң, бергәләп фикер алышып, әдәпле кешеләрдә булырга тиешле кайбер сыйфатларны искә төшерик. (чиратлашып һәр укучы үз фикерен әйтә укытучы тактага бу сүзләрне язып бара )
- - Өлкән яшьтәге кешеләргә, мохтаҗларга, гарипләргә һәрвакыт ярдәмчел, ихтирамлы һәм ихлас мөнәсәббәттә була.
- - Башкалардан үзен өстен итеп куймый.
- - Кеше хәленә керә белүчән
- - Сабыр, тырыш, әдәпле
- - Эшчән, хезмәт сөя

# Өй эше.

- 141 нче бит, 4 нче күнегү, язмача.
- 142 нче бит, 7 нче күнегү.